| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 31 октябре № 17

Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
3. «Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, беренче төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

I. Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Михайловка авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (каптажны ремонтлау).

II.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Михайловка авылында (Үзәк ур., Югары ур.) юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б, Михайловкаавылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы, Центральная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә,

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П. Бодряева